КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 август г.Казань № 882

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә балаларны уллыкка алырга теләүче затларны исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2012 ел, 8 февраль, 90 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә балаларны уллыкка алырга теләүче затларны исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2012 ел, 8 февраль, 90 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исеменә «уллыкка» сүзеннән соң «(кызлыкка)» сүзен өстәргә;

1 пунктка «уллыкка» сүзеннән соң «(кызлыкка)» сүзен өстәргә;

2 пунктка «уллыкка» сүзеннән соң «(кызлыкка)» сүзен өстәргә;

Әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә балаларны уллыкка алырга теләүче затларны исәпкә алу тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2012 ел, 8 февраль, 90 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 22 август, 882 нче
карары редакциясендә)

## Татарстан Республикасы территориясендә балаларны уллыкка алырга теләүче затларны исәпкә алу тәртибе

1. Әлеге Татарстан Республикасы территориясендә балаларны уллыкка алырга теләүче затларны исәпкә алу тәртибе (алга таба - Тәртип), Россия Федерациясе Гаилә кодексының 126 статьясындагы 2 өлеше, «Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында дәүләт белешмәләр банкы турында» 2001 елның 16 апрелендәге 44-ФЗ номерлы, «Шәхси белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федеральными законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе территориясендә балаларны уллыкка (кызлыкка) тапшыру һәм аларның яшәү шартларын һәм уллыкка алучылар гаиләләрендә тәрбияләнүне тикшереп тору кагыйдәләрен һәм Россия Федерациясе гражданнары булган һәм чит ил гражданнары яисә гражданлыгы булмаган затлар тарафыннан уллыкка алынган балаларны Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан исәпкә кую кагыйдәләрен раслау турында» 2000 елның 29 мартындагы 275 номерлы карары, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының "Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында дәүләт банкын формалаштыру, алып бару һәм куллану тәртибен раслау турында" 2020 елның 15 июнендәге 300 номерлы, "Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында мәгълүмат бирү буенча Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан гражданнарга ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында, аларны гражданнар гаиләләренә тәрбиягә бирү, Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда балаларны уллыкка (кызлыкка) алуга алдан рөхсәт бирү өчен федераль банктан белешмәләр бирү турында" 2020 елның 7 октябрендәге 554 номеры боерыклары, Татарстан Республикасы Гаилә кодексы, «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2008 ел, 1 декабрь, 843 нче карары нигезендә эшләрнде.

2. Тәртип Татарстан Республикасы территориясендә уллыкка алу хокукы булган затларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны уллыкка (кызлыкка) алырга теләүчеләрне исәпкә алуны оештыру кагыйдәләрен билгели.

Тәртиптә «Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында дәүләт белешмәләр банкы турында» 2001 елның 16 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән төшенчәләр кулланыла.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба - Министрлык) Татарстан Республикасы территориясендә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында белешмәләрнең дәүләт банкының төбәк операторы вәкаләтләрен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

4. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны уллыкка (кызлыкка) алырга теләүче затлар турында белешмәләрне исәпкә алу Татарстан Республикасы территориясендә, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында белешмәләрнең дәүләт банкын гамәли программа тәэмин ителешеннән файдаланып, түбәндәге вәкаләтле органнар тарафыннан белешмәләр исәпкә алу юлы белән гамәлгә ашырыла:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең балигъ булмаган затларына карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен башкаручы башкарма комитетлары (алга таба - опека һәм попечительлек органнары);

Министрлык.

5. Опека һәм попечительлек органнары түбәндәгеләрне исәпкә алалар:

Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары булган ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны уллыкка (кызлыкка) алырга теләүче Россия Федерациясе гражданнары;

Россия Федерациясе территориясеннән читтә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар, Россия Федерациясе гражданнары булып торучы һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче, шул исәптән баланың туганнары булган ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны уллыкка (кызлыкка) алырга теләүчеләр.

6. Министрлык түбәндәгеләрне исәпкә ала:

Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары булган ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны уллыкка (кызлыкка) алырга теләүче Россия Федерациясе гражданнары;

Россия Федерациясе территориясеннән читтә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны уллыкка (кызлыкка) алырга теләүче, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары булып торучы, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданы булган, шул исәптән ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган бала белән танышкан Россия Федерациясе гражданнары, әлеге гражданнар турында белешмәләр дәүләт банкына ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында һәм бу баланы

уллыкка (кызлыкка) алырга теләк белдергән (баланың туганнары булган гражданнардан тыш) белешмәләр кертүгә кадәр.

7. Балаларны үз гаиләләренә тәрбиягә алырга теләүче затлар турында белешмәләрне исәпкә алу Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында белешмәләрнең дәүләт банкын формалаштыру, алып бару һәм алардан файдалану тәртибен раслау хакында» 2020 елның 15 июнендәге 300 номерлы боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

___________________________